# Татарстан Республикасы
# Дәүләт Советы Президиумы
# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары вәкилләре киңәшмәсен чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының беренче утырышында карауга чыгарыла торган мәсьәләләрне алдан карап фикер алышу өчен 2014 елның 30 сентябрендә Казан шәһәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары вәкилләре киңәшмәсен чакырырга.

2. “Бердәм Россия” бөтенроссия сәяси партиясеннән депутатлыкка кандидатларның республика исемлеге буенча сайланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары вәкилләрен сайлауларны 2014 елның 29 сентябреннән дә соңга калмыйча күрсәтелгән депутатлар җыелышында үткәрергә.

3. “Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе” сәяси партиясеннән депутатлыкка кандидатларның республика исемлеге буенча сайланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары вәкилләрен сайлауларны 2014 елның 29 сентябреннән дә соңга калмыйча күрсәтелгән депутатлар җыелышында үткәрергә.

4. Бермандатлы сайлау округларыннан сайланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары вәкилләрен сайлауларны 2014 елның 29 сентябреннән дә соңга калмыйча 2014 елның 8 июлендәге 3658-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән расланган Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары вәкилләренең киңәшмәсе турындагы нигезләмәнең 4 пункты нигезендә күрсәтелгән депутатларның территориаль җыелышларында үткәрергә.

5. Бермандатлы сайлау округлары буенча сайланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының территориаль җыелышларын

әзерләүне һәм үткәрүне координацияләү эшен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының түбәндәге әгъзаларына йөкләргә:

1) 1 нче – 16 нчы бермандатлы округлар буенча сайланган депутатлар өчен Казан шәһәрендә – Ф.Х. Мөхәммәтшинга;

2) 17 – 23, 37, 42 нче бермандатлы округлар буенча сайланган депутатлар өчен Чаллы шәһәрендә – Р.А. Ратниковага;

3) 24 – 26, 34, 35, 38, 43, 44 нче бермандатлы округлар буенча сайланган депутатлар өчен Түбән Кама шәһәрендә – Р.И. Вәлиевкә;

4) 27 – 29, 32, 33, 36, 39, 40 нчы бермандатлы округлар буенча сайланган депутатлар өчен Әлмәт шәһәрендә – Т.П. Водопьяновага;

5) 30, 31, 41, 45 нче бермандатлы округлар буенча сайланган депутатлар өчен Зеленодольск шәһәрендә – А.П. Гусевка;

6) 46 нчы – 50 нче бермандатлы округлар буенча сайланган депутатлар өчен Лаеш шәһәрендә – Л.Н. Мавринага.

6. Депутатлыкка кандидатларның республика исемлекләре буенча сайланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының территориаль җыелышларын әзерләүне һәм үткәрүне координацияләү эшен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының түбәндәге әгъзаларына йөкләргә:

1) “Бердәм Россия” бөтенроссия сәяси партиясеннән депутатлыкка кандидатларның республика исемлеге буенча – Ф.Х. Мөхәммәтшинга;

2) “Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе” сәяси партиясеннән депутатлыкка кандидатларның республика исемлеге буенча – Х.Г. Миргалимовка.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2014 елның 22 сентябре
№ 3753-IV ДС